# ЧИШМӘ БАШЫ

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ»МБМББУ,декабрь, 2024 ел № 2





***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

## Газетаның сәхифәләре:

* Яңа елга теләкләр!
* Яңа ел турында шигырьләр
* “1дән 10га кадәр” (дидактик уен)
* “Светофорда кунакта” (сценарий)
* Яңа ел турында табышмаклар
* Кыргый хайваннар турында  ребуслар

***Баш мөхәррир:***
***балалар бакчасы мөдире –***
***Мостафина Рима Галип кызы***
***Мөхәррир урынбасарлары:***
***Музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф***
***Тәрбиячеләр:***
***Хөсәенова Р.Р.,Җәләлиева А.Г.***
***Шәкүрова Р.С.***




# ХӨРМӘТЛЕ ӘТИ-ӘНИЛӘР!

Декабрь бураннары алып килгән Яңа Ел белән котлыйм! Бәйрәмегез мөбарәк, ризык тулы өстәлегез түгәрәк, күңелле, куанычлы булсын. Эшләрегез уң булсын, күңелегездәге мәрхәмәтлелек нуры йөзегезне тагын бизәсен. Бусагаларыгыздан караңгылык, салкынлык, хәвеф-хәтәр атлап кермәсен, бәла-каза йөрмәсен. Бәхетле мизгелләр, матур вакыйгалар, яхшы хәбәрләр, саулык-сәламәтлек алып килсен Яңа Ел.

Гаилә бәхетегез учагы гел балкып торсын.

Ихтирам белән Мөндеш балалар бакчасы мөдире Мостафина Рима Галип кызы.

## Яшел чыршы

**Җәвад Тәрҗеманов**

Тышта буран бөтен җиргә карлар тутыра,
Безнең бүлмәдә ямь-яшел чыршы утыра.
Яшел чыршының очына йолдыз куелган.
Яңа елны каршыларга дуслар җыелган.
Бүген бәйрәм! Әйлән-бәйлән уйныйк-гөрләшик.
Бүген бәйрәм! Бәйләм-бәйләм бүләк өләшик.

## Чыршы әйләнәсендә

**Роберт Миңнуллин**

Каршылыйк, дуслар, бергәләп:
Яңа ел килә безгә!
Әнә күпме кунак килгән
Әйләнә – тирәбезгә.

Йолдызлар төшеп кушылган
Чыршыдагы утларга.
Кыш бабай белән Кар кызы
Килгән безне котларга.

## Чыршы

**Әхмәт Ерикәй**

Төрле-төрле утлар яна,
Без уйныйбыз, әйләнеп,
Бигрәк матур, бигрәк ямьле
Безнең чыршы бәйрәме.

Җырлый-җырлый әйләнәбез,
Чыршы тора уртада.
Кунак булып, ак сакаллы
Бабай килгән бәйрәмгә.

Чыршыдагы җем-җем утлар
Сүнәләр дә яналар.
Без җырлыйбыз, шатланабыз,
Без – бәхетле балалар!

## Кыш бабай килде

**Габдулла Тукай**

Урманнар, кырлар карга күмелде.
Кыш җырын җырлап «Кыш бабай» килде.
Чишмә, елгалар чылтырап акмыйлар.
Елгалар өстен бозлар каплыйлар.
Мамыктай карлар йөриләр очып,
Сөеп кызарта җил битнең очын.
Күңелле тышта ак кар өстендә
Чана шууы – һәркөн кич белән.






**Бакчада балаларның төп эшчәнлеге – уен. Тәрбия чарасы буларак уен – балаларның камилләшүенә, шәхес буларак формалашуына, үзгәрүенә этәргеч булып тора. Балага белем һәм тәрбия уен аркылы яхшырак бирелә.**

**Бала һәр предметны тотып карарга омтыла. Чын мәгънәсендә бала дөньяны "тотып карап таный". Предмет белән күбрәк хәрәкәт башкарган саен , бала аның үзлекләре турында күбрәк төшенә. Бала предметны тотып карап өйрәнгәндә, аны рәсеме буенча өйрәнүгә караганда, предмет, аның үзлекләре турында күбрәк төшенә, күбрәк информация ала икәнлеге ачыкланган. Балаларның математик күзаллауларын үстерү шөгыле өчен күрсәтмәлелек куллану, аларның саннар темасын тизрәк үзләштерүенә ярдәм итә. Шул уңайдан мин "1дән 10га кадәр" дип исемләнгән математик уен-китап ясадым. Уен зурлар төркеме өчен эшләнде.**

**Максаты: балаларның 1дән 10га кадәр саннар өйрәнүен ныгыту, геометрик фигураларны тану, төсләрне аеруны ныгыту.**



Китапны фитрдан эшләдем.

Һәр битенә ачык төсләр сайладым.

Балаларга мавыктыргыч булсын өчен төсле мәрҗәннәр белән биремнәр керттем. Саннарның икенче ягына ябыша торган тукыма беркеттем.

Һәр биттә үзенчәлекле биремнәр урнаштырдым. Мәсәлән: беренче биттә - вакыт берәмлекләрен белү өчен сәгать ясадым. Саннарын геометрик фигураларга урнаштырдым. Балалар шул саннарны дөрес итеп җыялар. Сәгатьнең телләре дә хәрәкәт итә. “Сәгать ничә?” дигән уен да уйнарга мөмкин.

Дүртенче биттә - төсле мәрҗәннәрне санап, саннарны дөрес итеп урыннарына ябыштыралар.

Бишенче биттә - пирамида бирелгән. Балалар аны дөрес итеп җыярга тиеш.

Алтынчы биттә – салават күпере төсләрен дөрес әйтергә өйрәнсәләр, сигезенче биттә геометрик фигураларны атыйлар.

Ахыргы биттә 2 кул ясалган. Балалар уң һәм сул төшенчәсен өйрәнәләр. Бармакларны бөкләп дөрес саннарны табалар.

Бу уен-китабым бик кызыклы һәм файдалы килеп чыкты дип уйлыйм.




Китапчыкның авторы:
Тәрбияче-Хөсәенова Рәзинә Равил кызы

# СВЕТОФОРДА КУНАКТА
## (сценарий)

**Тәрбияче: Балалар бүген балалар бакчасына килгәндә миңа хат ташучы очрады. Һәм ул миңа хат тапшырды. Укып карыйк әле ул хат кемнән икән? *(хатны укыйлар, светофор турында табышмак)***

**Тәрбияче: Балалар бу светофор, бик дөрес. Светофор Светофорович безне кунакка чакыра. Ләкин анда барыр өчен безгә төрле биремнәр үтәргә кирәк булачак. Сез әзерме балалар? Барабызмы?**
**Тәрбияче: Алайса әйдәгез биремнәрне үтик тә юлга кузалыйк!**
**1 нче бирем: “Табышмаклар”**
**•Автомобиль, трамвайдан**
**Саклан димен, бик сак бул!**
**Уйный торган урын түгел**
**Машиналар йөргән (юл)**
**•Тәрәзәле һәр ягы,**
**Җиргә тими аягы.**
**Сыртында бар дугасы,**
**Йә бу нинди юрга сон? (трамвай)**
**Тәрбияче: Әфәрин, балалар! Беренче биремне яхшы гына уздыгыз.**
**2 нче бирем: Сорау җавап дип атала.**
**Транспортта баручы кем дип атала? (пассажирлар)**
**Кечкенә балаларны транспортта йөртү өчен нәрсә таләп ителә? (Балалар кәнәфие)**
**Электр бн нинди транспорт йори? (трамвай, троллейбус)**
**Юл чатында нәрсә тора ? (Светофор)**
**Ә хзер әйдәгез 3 нче биремгә күчәбез.**
**Сезнең урындык астында яшел һәм кызыл түгәрәкләр бар. Мин сезгә “Транспортта үз-үзеңне тоту кагыйдәләре буенча сораулар бирәм. Әгәр дә минем фикер белән килешсәгез яшел түгәрәкне күтәрегез, әгәр дә килешмисез икән, кызыл түгәрәкне күтәрегез.**
**- Автобус, трамвай, троллейбуска арткы ишектән керергә кирәк!**
**- Автобустан чыкканда алгы ишектән чыгарга кирәк!**
**- Өлкәннәргә урын бирергә онытмаска кирәк!**
**-Транспортта морожный ашарга кирәк!**
**Тәрбияче: Балалар менә без Светофор Светофорыч янына килеп җиттек.**
**Светофор: Исәнмесез, балалар! Биремнәремне үтәдегез, юл кагыйдәләрен беләсез икән. Хәзер мин сезнең игътибарыгызны сынап карыйм әле. Бер уен уйнап алабыз. Башта әйтегез әле минем кызыл утым нәрсәне аңлата? (тукта). Сары утым нәрсәне аңлата? (Әзерлән). Яшел утым нәрсәне аңлата ( Чыгарга ярый).**
**Светофор: Молодцы, балалар! Сез бик игътибарлы икәнсез.**

**Җыр: “Светофор”**

**Светофор: Сез балалар бик тырыш, игътибарлы икәнсез. Урамнарда йөргәндә бу билгеләрне онытмагыз! Юлларда игътибарлы булыгыз! Юл кагыйдәләрен бозмагыз! Ә мин яңадан юл чатына, юлда тәртип урнаштырырга китәм! Сау булыгыз!**

**Сценарий авторы:**
**Тәрбияче – Шәкүрова Рокыя Сәүбән кызы**

## ТАБЫШМАКЛАР:

1.Кышын тауда шуалар, җәен җыеп
куялар. Нәрсә ул? (Чана)

2. Ике агай тездән,
Калышмыйлар бездән. (Итек)

3. Йолдыз, йолдыз вак кына,
Яфраклары ак кына.
Өс киемеңә куна,
Тәнгә тисә су була (Кар бөртеге)

4. Үкерә дә, котыра,
Бөтен җирне тутыра. (Буран )

## РЕБУСЛАР:

**Беренче хәрефләр буенча сүзләрне укы**




**Төзеде:**
**Тәрбияче-Җәләлиева Айгөл Госман кызы**